16. Isənbət, N. (1989). *Sin sazyңny uinadyң: "Moңlanyp ai nurlarynda…"* [You Played Your Song: "Sighing in the Moonlight..."]. Isənbət N. Sailanma əsərlər 4 t. 1 t. 110 p. Kazan, Tatar. kit. nəshr. (In Tatar)
17. *"Shəhri Kazan: tygərək өstəl"* (1995) ["The City of Kazan: A Round Table"]. Yazmany Rəmis Aimət həm Əg"zam Fəizrakhmanov əzerləde. Shəhri Kazan. 11 apr. (In Tatar)
18. *Radiotapshyru Ilham Shakirovka 60 yash'* (1995) [The Radio Broadcaster Ilham Shakirov Is 60 Years Old]. Alyp baruchy – muzyka belgeche I. Isənbət. Tatarstan radiosy arkhivynnan. URL: https://vk.com/dtrk_tatarsatan?ysclid=m9s3xd444b754100359 (accessed: 20.02.2025 ). (In Tatar)
19. Isənbət, N. (1971). *Televizor aldynda uilanular* [Thinking in Front of the Television]. N. Isənbətneң shəkhsi arkhivynnan. 20 p. Kul'yazma. (In Tatar)
20. Səfərgaliev, R. (2010). *Ilahi əmer belən dөn'yaga kilgən talant* [A Talent Born by Divine Decree]. Kazan utlary. No. 2, pp. 111–113. (In Tatar)
21. Abdullin, A. Kh. (1971). *Tatarskaya narodnaya pesnya : Tematika, zhanry i nekotorye osobennosti narodnogo ispolnitel'stva: dissertatsiya ... kandidata iskusstvovedeniya: 17.00.00* [Tatar Folk Song: Themes, Genres and Some Features of Folk Performance: Ph.D. Thesis]. Leningrad, 258 p. (In Russian)

---

# НӘКЫЙ ҺӘМ ЙОЛДЫЗ ИСӘНБӘТЛӘРНЕҢ ТАТАР ҖЫРЫ ҺӘМ ИЛҺАМ ШАКИРОВКА КАРАШЛАРЫ

**Миләүшә Мөхәммәтҗан кызы Хәбетдинова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
mileuscha@mail.ru.

**Айнур Касыймҗан кызы Машакова,**
М.О.Ауэзов исемендәге әдәбият һәм сәнгать институты,
Казахстан, 050010, Алматы ш., Курмангазы ур., 29 нчы йорт,
a_mashakova@mail.ru.

2025 елда «җыр дәүләте ханы» – Илһам Шакиров тууына 90 ел тулды. Безнең халыкта: «Йолдыз ерагайган саен яктырак яна», – дигән гыйбарә бар. Бу сүзләр абруйлы җырчыга тулысынча туры килә.

Әлеге мәкалә Нәкый һәм Йолдыз Исәнбәтләрнең татар җырларының милли үзенчәлекләренә, Илһам Шакировның җырчылык осталыгына багышланган фикерләрен туплап төзелде. Хезмәтнең яңалыгы – фәнни әйләнешкә яңа чыганаклар кертүдә.

Илһам Шакировның «Халык моңнары» исемле мәкаләсе бар. «Халык җырлары – сәнгатебезнең иң кыйммәтле хәзинәләреннән берсе. Шуңа күрә аларны җыю, эшкәртү һәм аерым җыентыклар итеп чыгаруга зур әһәмият бирелә», – дип яза җырчы үзенең бу хезмәтендә (Цит. [1, б. 92]).

Татар халык җырларын күзәтеп баруы һәм профессиональ милли музыканы үстерү перспективалары хакында Нәкый Исәнбәт берничә хезмәтендә бәян итә. (*Кар*.: [2], [3], [4], [5], [6]) Галимнең архивында «Татар музыкасы энциклопедиясе»нең тәмамланмаган кульязмалары саклана. «Бер татар авылының моннан йөз ел элек язылган җыр-көйләре» (1966) мәкаләсендә галим үзенең халык җырларын текстологик эшкәртү принциплары белән уртаклаша [7].

«Җыр – көй һәм аны җырлау, билгеле, һәр милләт өчен үзенчәлекле әйбер. Һәр халыкта булган шикелле татар җырлавында да үзенә генә хас йолалар, үзе яраткан алымнар,

манерлар бар», – дип яза «Ф. Кудашева концертлары» (1959) исемле мәкаләсендә Нәкый Исәнбәт [6].

Күренекле фольклорист әле дә басылмаган «Татар музыкасы турында» дигән гыйльми хезмәтендә: «Халыкның көйләре, иҗаты – беркем тарафыннан да боерыксыз, көчәнүсез, ирекле, күңелдән туган иҗат. Моны бары җир астыннан тышка бәреп чыккан саф салкын чишмә булып, үз таты, үз тәме, үз матурлыгы белән туып һәм агыш юлын үзе табып, үз әйләнәсе аваз һәм күренеш белән матурлап, сугарып, агып яткан бу чишмәгә тиңләргә була. Кечкенә чишмәдән Агыйдел, Җаек, Инзәр, Йөрүзән, Әй, Зәй, Сакмар, Камалар, өлкән Иделләр хасил булганын күрәбез, аның бу диңгезгә кадәр күпме гүзәл юллар чабып, өлкән диңгезгә барып тоташу мөмкинлеге бар, шуның куәте бар, Агыйделгә Уралның Ирәмәл тау итәгеннән кечкенә чишмә булып чыкканда ук салынган бит! Чишмә алган менә шулай халык күңеленнән ямьле Агыйдел, Сакмар, Салкын чишмәләр, Карурманнар гасырларча агып, күңелләрне сугарып торалар, алар үлемсезләр. Аларга халык тәкъдире салынган, халык көе, димәк. Татар күңеленнән үз шатлыгы, үз кайгысының эчтән ташып, чишмә кебек агып-агылып, яки ялкын кебек кабынып чыккан табигый иҗат, һич көчләүсез, кампаниясез, акчасыз, кәсепсез – аның мокатдәс күңел чыгышы, шуның тәкъдире. Син теләсәң, аны Европа яки башка музыка системы ноктасыннан караганда, аларга сыешмаган өчен гаеплә, тездән үтеп булган кичүен тапта, сай диген, тиргәгән бул, әмма ул төп нигез музыка һәм елгаларыбызның аның булачак диңгезләренең ассәсе. Ул бу диңгезгә озак гасырлар халкыбызның аң-зарын, эчкерсез моңын, шатлык-кайгысын койган инде», – дигән нәтиҗәгә килә [8, б. 12].

Җырчы Фәридә Кудашева осталыгы турында уйланганда, Нәкый Исәнбәт моң төшенчәсенең мәгънәсен түбәндәгечә ачыкларга омтылган: «Татар халкы җырчының тавышын һәм җырлый белү осталыгын бәяләгәндә моң сүзе куллана. Нәрсә соң ул моң?... халык бу сүзне бик конкрет һәм ачык мәгънәдә куллана:

– Аның тавышы моңлы, тегенең – моңсыз яки бу моңлы җырлый – дип кенә куя.

Моң нәрсә? – дигәнгә, билгеле, монда тукталып торып булмый. Тик шунысын гына чамалап була: бу моң дигәннәре чыннан да күпьяклы һәм бик хикмәтле нәрсә булырга кирәк» [6].

Рецензиядә галим моңлы җырлый белүнең алымнарын да анализлап чыга: «... безнең көйләребездә, бигрәк тә озыннарында, Агыйдел, Зөя, Зәй тугайлары кебек бик нәфис бөгемле чигешләр, нечкә борылмалар бар икән. Мондый нечкә борылмаларны элек кич утырган кызлар бәлки калфак чигешләрендә үз куллары белән чигеп тә бирә белгәннәрдер? Моңлы җырлый белүнең хикмәтле бер үзенчәлеге дә көйнең шул нечкә борылмаларын үз иңнәрендә ала белүдә түгелме икән? Гадәттә, бездә көнбатыш музыка тәрбиясе алган күп кенә җырчыларыбыз тавышны идарә итүдә зур техник осталыкка ия булсалар да, никтер, көйнең әнә шул борылма һәм уемнарына тиешенчә әһәмият биреп җиткермиләр шикелле. Шуңардырмы, алар көйнең үз борылмаларына кермичә, аның тугайларын әйләнмичә, берсеннән-икенчесенә турыдан гына үтеп йөрергә яраталар. Мондый йөрештән көйнең табигый агышы бозыла, көй урынына берничә туры һәм сынык сызыкта алынган тавыш кына торып кала. Бу очракта, билгеле, моң хакында сөйләргә туры килми. Монда инде сахра һәм Идел тугайларында йөрү урынына үзеңне ниндидер төз генә кәнсәләр коридоры һәм шуның текә борылмалары арасында йөргән кебек хис итәсең.

Бар бездә – көчле тавыш белән зур тамаша залларын тутыра алучы җырчыларыбыз. Бар – үтә күренеп торган саф тавышлылары. Бар – төссезләре дә» [6].

«Җырны җырлаганда безнең халык җырчыдан көй белән бергә күңел тавышын, анда салынган хис байлыгын, ягъни көйнең эчке җанын, шуның хәрәкәтен, динамикасын да сорый. Моң дигән хикмәтле нәрсә ул шул җанга үтеп керү алымнары һәм традицияләре белән үрелгән булырга кирәк, – дип нәтиҗә ясый Нәкый Исәнбәт. – Шулай булгач, моң дигәнне кайберәүләр кебек, кайгы-сагыш мәгънәсендә аңларга ярамый. Ул монда ихтыяҗ мәгънәсендә килә. Ягъни, моң ул – халыкның күңел ихтыяҗын үти».

Нәкый Исәнбәт татар җырчыларның төрле манерлары һәм милли алымнары булганын дәлилләп чыга:

«Безнең опера һәм филармония сәхнәсендә, радиода яхшы танылган җырчыларыбыз бар. Халык аларны төрлесен төрле яктан таный һәм төрлечә бәяли. Чөнки җырчыларның җырлый белүләре, тавыш тембры, моңлылыклары төрле

булып кына калмыйча, монда тагын аларның җырлау манерлары һәм алымнары төрле булуын да өстәргә кирәк. Мәсәлән, бездә озынлы-кыскалы көйләрне җиңелчә һәм такмакча сикертеп, тавышны өстән генә сибеп йөртеп, шадралатып җырлау алымы бар. Бу форма бездә татар җырчылыгының төп милли үзенчәлеге, аның төп тарихи традицион алымы дип күрсәтергә омтылулары да юк түгел. Бар – колоратуралы итеп, ягъни төрлечә сайрап, чутылдап җырлау. Монысы көнбатыштан кергән һәм аның бездә шактый уңышлары бар. Бар – авылча урам әйләнеп, салмакка кычкырып җырлау алымы. Бар – гармун тавышы үрнәгендә тамак төбе белән эчке җырлау... Бар тагын, җырлау урынына, Саратовский гармунга буйдан-буйга бер генә тавыш белән кычкырып тору... » [6].

Нәкый Исәнбәт үз хезмәтләрендә ялган халыкчанлык проблемасын да күтәреп чыга. Борчылып, ни дәрәҗәдә бу эш безнең мәдәнияткә зыян китергәне турында фикер йөртә:

«Бар тагын ике телне бергә бутап җырлау. Үкенечкә каршы, соңгы вакытта кайбер җырчыларыбыз тарафыннан бу жаргончылыкны «Горький өлкәсенең халык җырлавы» дигән исем астында сәхнәбезгә кертеп, кеше көлдереп кул чаптырырга тырышу кебек күңелсез күренешләргә дә очрарга туры килә. Ләкин, турысын әйткәндә, болай җырлауда бер төрле дә халыкчанлык юк, ул бары тик тел бозып сөйләүче Казан шалманнары арасындагы бер җырлау кыланышы гына. Без стилягачылыкка каршы ничек көрәшсәк, халык телен һәм җырчылык сәнгатен мыскыл итү өчен юри алып барылган бу жаргончылыкны сәхнәбезгә сөйрәп кертергә маташучы халтурачыларга каршы шулай ук ныклы көрәш алып барырга тиешбез» [6].

Галим фикеренчә, татар җырчысының осталыгы аның озын көйне җырлый белүендә сынала.

«Монда күп нечкәлекләр бар. Мәсәлән, көй буыннарын бер үлчәүдә симметрия саклап, салмак кына сузып җырлау бар, шулай ук кайбер тактларында тавышны бушатып, кайберләрендә тиз һәм кыю күчешләр ясап, аерым басым ясап җырлаулар бар. Соңгысы бигрәк тә башкорт җырчылары арасында урын алган һәм ул динамик булуы белән хискә тагын да ныграк тәэсир итүчән. Кыскасы, җырлау алымнары үзе күп төрле булып, моңа тагын шәхси манерлар да килеп кушыла, димәкче булам. Җырчыларның көй сайлаулары да шуңа карабрак була. Эшнең бу ягы гомумән татар көйләренең музыкаль үзенчәлекләренә дә бәйләнгән булып, монда эш тагын да катлаулырак» [6].

Илһам Шакиров исеме татар милли вокал сәнгате тарихында тулы бер чорны били. Һичшиксез, бу уникаль кешенең шәхесе тикшеренүчеләр – тарихчылар, музыка белгечләре, җырчылар һ.б. игътибарын җәлеп иткән һәм җәлеп итүен дәвам итә (кар. [1], [9], [10], [11]). Әлбәттә, Илһам Шакиров – зур талант иясе. Аның талантының табигате нәрсәдә? Бу сорауга җавапны да без Нәкый һәм Йолдыз Исәнбәтләр хезмәтләреннән табарга булдык.

1968 елда Илһам Шакиров Нәкый Исәнбәтне Тукай премиясенә тәкъдим иткән [12]. Бу мәкалә – ике шәхеснең бер-берсен ни дәрәҗәдә хөрмәт иткәне билгесе. Алар арасында иҗади хезмәттәшлек булганын без «Илһам мине дә өлешсез калдырмады», – дигән фикердән чыгып әйтә алабыз. Бу сүзләрне бөек фольклорист И. Шакировны 50 еллык юбилее белән котлаганда әйтә (Цит. [1, 41 б]).

1948 елның 6 апрелендә СССР һәм Финляндия арасында дуслык, хезмәттәшлек һәм үзара ярдәм турында шартнамә имзалана. Ә 1967 елның апрелендә ТАССР белән элемтәләрне җайга салу белән шөгыльләнүче Габдулла Тукай исемендәге җәмгыять (Abdulla Tukain Seura ry) оештырыла. 1968 елда Финляндиядәге Тукай җәмгыяте җитәкчесе Өмәр Таһир чакыруы буенча, бер төркем татар сәнгате әһелләре (Айрат Арсланов, Марат Әхмәтов, Марс Макаров, Илһам Шакиров, Венера Шәрипова, Рөстәм Яхин) 21–29 май көннәрендә[1] чит илгә сәяхәт кыла. Татар артистлары Хельсинкидә һәм Тампер шәһәрләрендә чыгыш ясыйлар [13]. Көн саен Финляндия татарлары аларны кунакка дәшәләр. Татар җырларын җырлап, Советлар Союзы татар дөньясының соңгы яңалыклары белән кызыксынып, ике ил татарлары бик җылы итеп аралашканнар (Тулырак бу турында: [14]).

1917 елда яшь Нәкый Исәнбәт «Балалар дөньясы»нда «Туган ил» исемле шигырь бастырган була [15]. Илһам Шакиров бу әсәр көен Финляндия татарларыннан әлеге ил буйлап гастрольләр вакытында ишетә һәм

1 «Илаһи Илһам» китабында татар артистлары делегациясенең Финляндия президенты Урхо Калева Кекконен белән очрашу көне 1968 елның 18 августы дип күрсәтелгән [1, 25 б.].

җырлап йөри башлый. Шулай итеп, «Туган ил» көе татарларга Нәкый Исәнбәт сүзләре белән кире кайтарыла.

Күренекле шагыйрь һәм җырчы-композитор бергә тудырган тагын бер әсәр бар. Ул – Нәкый Исәнбәт тарафыннан 1922 нче елда иҗат ителгән[1] «Син сазыңны уйнадың» [16] дигән әсәр. Илһам Шакиров көйгә салган бу җыр әле дә халык күңелендә үз урынын били килә [1, б. 41].

Нәкый Исәнбәт бу талантлы җырчыга җитди бәяләмә биргән: «Татар җырчылык тарихында үзенә аерым эз һәм мәктәп тудыра алган җырчыларыбыз, баксаң, күп түгел. Шулар арасында халыкта аеруча зур мәхәббәт һәм дан казанганы, әлбәттә, Илһам Шакиров.

Аның төрле көйләргә җырлаган җырлары йөзләрчә исемдә пластинкаларда халыкка таралган. Күптәнме әле бездә:

– Безнең җыр-көйләребездә моң дигән нәрсә юк, моң дигән төшенчә үзе үк буш сүз ул, әнә бит, Европа музыкасында андый термин үзе дә юк. Инде Тукайлар заманында булса, анысы, ул андагы изелгәнлек галәмәте генә. Хәзер – революция. Шулай булгач, андый искергән алымнар белән сузып-сузып җырлаулар кемгә кирәк? Ул бүгенге рухта ят. Хәзер әнә бит темп ничек! Кара син ничек негрлар джазга басалар? – дип әйтәләр иде. Янәсе, нәтиҗәдә бездә дә кайбер җырчыларыбыз, шул юлга басып, кемнәргәдер охшарга тырышып, җырда да, сөйләү катыш бертөсле шыңшып җырларга, җыр арасында, һич кирәк булмаса да, баскычларга менеп-төшеп йөрергә, хәтта, юньләп бии белмәсәләр дә ялтыравыклы тәңкә шәүләләре эчендә шул җыр арасында ук биегән кебек кыланып алырга, кыскасы, сәхнәдә җыр сәнгате урынына арзанлы эффект күрсәтү белән шөгыльләнергә тотындылар һәм шуны «заманчалык», дип аклана башладылар.

Менә Илһам Шакиров шул модачылык, шул каршылыклар эчендә татарның үз халык җырчылыгы, һәм шуның гасырлар буена килгән үз милли формасы, үз халыкчан тарихы традициясе булуын яклап чыкты һәм гамәлдә үзенең җырчылык таланты, үз җырга осталыгы, халык рухында җырлый белүе белән бу көрәштә җиңеп чыкты. Чөнки ул халык моңын яклаган кебек халык та аны зур алкышлар белән котлап каршы алды һәм алмакта.

Илһам бернинди ясалма эффектларсыз, хәтта кайбердә үзен гармун йә оркестр белән дә озаттырмыйча, бер башына ялгыз гына чыгып борынгы озын, моңлы «Карурман» көен җырлап гаять зур алкышлар алуга иреште. Ул халыкның гел җиңел такмакка сикереп биеп кенә яшәмәвен, һәркемнең язмышында үз кайгы-сагышы булган кебек, моңланырга да хакы булуын яклап чыкты. Чөнки Илһам үзенә генә хас матур моңлы тавышлы һәм халыкчан аһәңле, талантлы оста җырчы булып кына калмый, ул татар көйләренең җыр-моң, милли үзенчәлекләре турында да тирән уйланучы җырчы.

Әйтергә кирәк, ул хакта үз мәктәбенә, үз теоретик нигезләренә ия кеше. Ул – аның пропагандисты. Шунлыктан татар музыкасында Сәйдәш ничек үзенә хас урын тотса, җырчылыкта Илһам да шундый урын тота диючеләр ялгышмыйлар. Илһам Шакиров, әйткәнемчә, күп төрле көйләр җырлады һәм җырлый. Аның репертуары бай. Шулар арасында безнең өчен иң кадерлесе, әлбәттә, әлеге «Карурман», «Тәфтиләү», «Әллүки», «Чатырлар», «Сәгать чылбыры» һәм тагын шулар кебек тарихи озын, моңлы көйләребез. Ләкин Илһам бу традицион мәгълүм көйләребез белән генә чикләнеп калмады, ул керәшен татарлары арасында сакланып калган борынгы «Бик еракта идек без», «Бер алманы бишкә бүләек» кебек моңлы көйләребезне дә җырлап чыгып, популярлаштырды. Шулай ук композиторларыбызның да татар аһәңле көйләрен читләтеп калдырмады. Әйтик, композитор Салих Сәйдәшевнең «Хуш, авылым», композитор Рөстәм Яхинның Гөлшат Зәйнашева җырына язылган мәшһүр «Сандугач» көен, Сара Садыйкованың «Өченче көн тоташ кар ява»сын, Илдус Якуповның Әхмәт Ерикәй шигыренә язган «Яшьлегемә йөгереп кайтыр идем» көйләрен Илһам тиңдәшсез бер осталык белән җырлый. Шулай ук үзе дә матур-матур көйләр чыгаргалый» [1, б. 41].

Күп вакытта Мәскәү өчен әзерләнгән тапшырулар, концерт формасы белән чикләнмичә, музыка белгечләренең аңлатуларында бара, һәм бу тыңлаучыларга татар музыкасын тирәнрәк төшенергә ярдәм итә. Абруйлы музыка белгече Йолдыз Исәнбәт – Илһам Шакиров иҗатының юл башында ук аның бөеклеген таныган, исбат иткән шәхес. 60 нчы елларда ул җырчы турында Үзәк телевидение өчен тапшыру әзерләгән. Аның бәяләмәсендәге «Шакиров – непревзойденный исполнитель татарских песен» дигән менә бу

[1] Сайланма әсәрләрендә бу әсәр 1925 нче елда язылган дип билгеләнгән.

җөмлә кайбер худсовет әгъзаларында зур канәгатьсезлек тудырган. Берничә җыелыш җыеп, алар бу эпитетны тапшыруда кулланмаска дигән нәтиҗә дә чыгарганнар.

Мондый тискәре күренешләрнең еллар узгач та юкка чыкмаганлыгы күренекле танылган музыка белгече Йолдыз Исәнбәтне нык борчый. Ул интервью, мәкаләләрендә кайбер музыкантларларның көнчелектән Илһам Шакировка таш атканнары турында да уфтанып яза. 1995 елда Илһам Шакиров юбилее уңаеннан әзерләнгән әңгәмәсендә ул: «Композитормы ул, пианистмы – бөтенесе үзен Шакиров белән чагыштырып, аны кимсетеп, үзен зуррак итеп күрсәтергә тырышты. Күрәсең, күпсенәләр», – дигән фикерен әйткән иде [17].

Шушы юбилей уңаеннан, Йолдыз Исәнбәт тарафыннан радиотапшыру да әзерләнгән булган. Әлеге тапшыру барышында ул бөек җырчының иҗатын күздә тотып, эчке горурлык белән тамашачыларга: «Ләкин тормыш раслады: сәнгать үлчәве белән килгәндә, Илһам Шакиров ул вакытта да «непревзойденный» иде, әле дә «непревзойденный» булып тора. Дөрес, сәхнә уңышы, халык арасындагы популярлык буенча аны вакыт-вакыт узып китүчеләр дә булды, ләкин мин бит сүзне сәнгать турында алып барам. Артистны мода да бик популяр итү мөмкин, ә халык мәхәббәтен казану һәм дистәләрчә ел югалтмау – ул инде бөтенләй икенче нәрсә.

Илһам Шакировның безнең сәнгатьтә токтан урыны аның зур шәхес булуыннан килә, ул халык арасында музыка дөньясында ихтирам казанган чиксез талантлы музыкант, укымышлы, белемле, фикер йөртүче, киң күңелле, матур табигатьле кеше, аның кыйбласы бар», дигән фикерен җиткерә [18].

Йолдыз Исәнбәт, фикерен дәлилләү өчен, радиотыңлаучыларга Илһам Шакиров башкаруында сирәк җырлана торган «Зөлхиҗҗә» исемле озын көйне тәкъдим итә. «Хатлар укыганда» дигән музыкаль тапшыруның халыкка булган тәэсире турында уйланганда, Нәкый Исәнбәт бу җырга бик матур бәяләмә бирә: «“Зөлхиҗҗә” – элеккеге моңлы, озын башкорт көйләреннән берсе. Әйтергә кирәк, безнең татар халкы башкорт көйләренең барысын да үз репертуарында йөртми. Әйтик, “Баранбай”, “Биеш”, “Колый кантон” кебек озын матур көйләр бездә җырланмый. Әмма “Ашказар”, “Искадрон”, “Зөлхиҗҗә” кебек җырларны бездә бик яратып тыңлыйлар. Хикмәт нидә? Күрәсең, бу көйләрдә безнең борынгы озын татар көйләре белән пентатоник алымнарда аһәңдәшлек, интонацион уртаклык, кардәшлек зур», – дигән нәтиҗәгә килә энциклопедист-галим. – «“Зөлхиҗҗә” шулай бездә яратылып җырланса да, ул сирәк җырланыла торганнардан. Чөнки бу нечкә чигешле, нюансларга бай, киң колачлы, моңлы озын көй теләсә кем башкарып чыга ала торганнардан түгел» [19, б. 5].

«Илһам Шакировның иҗаты күпкырлы», – дип әйтә Йолдыз Исәнбәт радиоташыруда. Җырчының «иң зур казанышы булган халык көйләрен башкару сәнгатенә» керткән яңалыкларын радиотапшыруда алып баручы буларак билгеләп үтә: «Татар халык музыкасын башкару традицияләрен үстереп, Илһам Шакиров татар музыка сәхнәсенә бик күп яңалыклар кертте» [18].

Әлбәттә, тапшыру вакыты чикле булу сәбәпле, әлеге проблеманы бер чыгарылыш кысаларында чишәргә җиңел түгел, шулай булса да Йолдыз Исәнбәт бу эшне тиешле дәрәҗәдә башкара алган. Ул бер тапшыру барышында Илһам Шакировның җиде яңалыгы белән таныштыра. Без аларны биредә кыскартып тәкъдим итәргә булдык:

1. «Әйтик, ул халык көйләрен микрофон белән җырлауны башлап җибәрде… Кайчан да булса микрофон татар музыка сәнгатенә дә кереп урнашырга тиеш иде. Ләкин микрофон белән иң беренче булып Илһам Шакиров җырлый башлавы бу вакытларда бик сәер тоелды. «Бер уйласаң, аңа микрофонның бер кирәге юк иде, чөнки киң сулышлы, чын мәгънәдә җырчы тавышына ия артист». «Ә Илһам Шакировны алсак, ул консерватория тәмамланган профессиональ җырчы, ул бөтен дөнья классик репертуарының катлаулы әсәрләрен башкарачак музыкант итеп тәрбияләнде... Ул консерваторияне, теләсә, опера театрында эшли алырлык җырчы булып тәмамлады. Аның тавышы сәхнә алдында утырган симфоник оркестр яңгырашын каплап, зур театр залын тутыра иде. Нигә кирәк булды соң аңа микрофон? Бу мәсьәләнең тагын бер ягы бар. Тыңлаучыларның күңелен Илһам Шакировның микрофон белән җырлый башлавы җәрәхәтләндерде. Микрофон татар музыкасы сәнгатенә ят нәрсә кебек кабул ителде. Илһам Шакировны бүтән халыклар җырчыларына ияреп, татар музыкасын бозуда гаепләделәр. Яшь җырчыга залдан: «Микрофоныңны ташла!», – дип кискен боерык

биреп кычкырулар да еш булды. Шулай бер вакыт мондый кычкыруларга Илһам Шакировның сабырлык белән «Стамбул булып Стамбул мәчетләрендә, микрофон аша азан әйтеп, мөселманнарны намазга чакырганда, татар халык көен микрофон белән җырлау артык гөнаһ булмас…» дип җавап бирүе хәтеремдә. Инде микрофон җырчы тормышын җиңеләйткән икән, кайбер өстенлек мөмкинлекләр биргән икән, Илһам Шакиров, заманнан калышмыйча, моннан файдаланды» [13].

2. Илһам Шакиров җырлый башлаган вакытларда, татар халык көйләрен башкаручы филармония җырчылары я баян, я кайвакытта гармун белән чыгыш ясыйлар иде. Бүтән музыка кораллары кулланылмады диярлек. Дөрес, татар композиторлары халык көйләрен фортепиано яки симфоник оркестр белән җырлау өчен дә шактый эшкәрттеләр. Ләкин андый әсәрләрнең саны бөтен җырчылар репертуарын тәэмин итәрлек түгел иде, һәм алар халыкча җырлаган филармония артистларына түгел, ә академик рухта җырлаучы опера һәм камера җырчыларына билгеләнгән иде. Илһам Шакиров татар халык көен чын халыкча җырлап, үзенең тавышын төрле типтагы оркестрлар һәм музыка кораллары тавышы белән бик матур һәм зәвыклы итеп куша алды. Бер уйлауда, фортепиано белән җырлаумы, баян беләнме?!… Ни аерма? Музыка тәрбиясе алган җырчы өчен монда бернинди авырлык юк, ләкин бит эш ансамбльне бозмыйча, бергәләшеп җырлау, уйнау турында гына түгел, ә бер бөтен сәнгать әсәрен тудыру турында, мәгънәви һәм эстетик бердәмлек турында. Халыкчан, димәк авылчарак җырлаучы кеше тавышы һәм гасырлар буе камилләшкән европа профессиональ музыка кораллары тавышлары бер-берсенә туры килергә тиеш. Шуңа күрә фортепиано яки оркестр белән җырлау җырчы тавышына, аның сулышына, тавыш алу рәвешенә өстәмә таләпләр куя. Җырчы тавышы милли классик интернациональ музыка коралларына тиң булырга, шул ук вакытта милли үзенчәлекне сакларга тиеш. Моңа ирешү авыр. Бөтен илләрдә халыкча җырлаучы артистлар, гадәттә, милли музыка кораллары белән генә җырлыйлар. Илһам Шакировның дулкынлы тавышы, аның җырлау алымнары татар халык музыкасы аһәңнәрен симфоник оркестр һәм фортепиано яңгырашына бик табигый кушып җибәрде. Бу җырчының милли рухны, милли моңны саклавыннан гына түгел, аларны ниндидер яңа югарылыкка күтәрү, аларга яңа мәдәни форма бирүдән дә килә. Илһам Шакиров белән чыгыш ясаган музыкантларның дәрәҗәсе югары булуын да онытырга ярамый. Әйтик фортепиано белән җырлаганда Илһам Шакиров нота буенча җырламый, ул халык көен ирекле башкара, шуңа күрә пианист та татар халык көенең эчке агышын тоеп, җырчының шул көйне кайсы якка борып җибәрүен алдан сизгән талантлы музыкант-импровизатор булырга тиеш. Кем соң ул пианистлар? Радио концертмейстеры Екатерина Соколова, опера театры дирижеры Тәлгать Әхмәтов. Һәм өч татар композиторы: Александр Ключарев, Рөстәм Яхин, Ренат Еникеев. Мондый иҗади дуслык, әлбәттә, татар халык музыкасының эчке мөмкинлекләрен ачарга, аңа яңа төсләр бирергә юл ача» [18].

3. «..җырчының тагын бер үзенчәлекле яңа алымына игътибар итәсе килә: ул сүз әйтмичә генә көйләү, җырсыз көйләү. Бү эстрадада шактый еш очрый торган әсәрнең берәр куплетын сүзсез, лә-лә-ләгә яки сызгырып кабатлауга кайтып калмый. Илһам Шакиров көйнең формасын, төзелешен, бүлекләрен саклый, ләкин көйне үзен кабатламый, ә аңа нигезләнеп яңа, кайвакытта бик катлаулы көй тудыра һәм шундый урыннарда төрле алымнар кулланып, вокаль техникасын да күрсәтә. Бер караганда монда джаз йогынтысын күреп була, ләкин Илһам Шакировның импровизациягә килүе джаздан түгел. Импровизациядә ул халык көенең үзендә булмаган, ләкин җырның эчтәлеге таләп иткән хисләр һәм төсмерләр эзли. Халык көе ул бит тирән булса да, ләкин бер хисне тасвирлый. Көйне яңа сүзләр белән кабатлау, шул хисне яңадан-яңа исбат итү, ниндидер дәрәҗәдә көчәйтү, ләкин күп кенә кабатлама, шул төп хистән китеп булмый. Илһам Шакиров импровизацияләрендә (ул аларны вокализ дип исемли) әсәргә яңа хисләр кертә, аның эчтәлеген тирәнәйтә, өстәмә мәгънә бирә, эмоциональ баета. Ә, бәлки, халык музыкасы һәм татар репертуарына гына таяну кайвакытта Илһам Шакировка үзенең җырлау мөмкинлекләрен, артист талантын тулысынча ачуын чиклидер һәм ул вокализларда үз сүзен әйтү юлын эзлидер» [18].

4. «Татар халык көйләрен эстрада оркестры яки инструменталь ансамбль белән җырлауны да безнең сәнгатькә Илһам Шакиров кертте. Аның белән бер вакыттарак инструменталь ансамбльләр белән Әлфия

Авзалова да җырлый башлады, ләкин аның репертуары бөтен дөнья халыклары җырларына нигезләнгән иде. Чит ил җырларын, безгә чит илдән кергән инструменталь ансамбль белән башкару табигый күренде. Ә Илһам Шакировка бик күп ризасызлык белдерелде. Халык инструменталь ансамбльләрне тыңларга әзер түгел иде, чөнки безнең ил өчен эстрада тибында инструменталь ансамбльләр, гомумән, шактый яңа нәрсә иде. Ә инде татар музыкасына алар әле бөтенләй кермәгән иде.

50 нче елларда Олег Лундстрем җитәкчелегендәге оркестрның бер-ике концертыннан соң татар композиторларының әсәрләре җиңелчә эстрада манерасында язылмады да, башкарылмады да. Мондый оркестр-ансамбльләргә ничектер өстәнрәк карадылар, аларга инде лаеклы урын – ресторан, күңел ачу җирләре, ә чын татар сәнгать әсәрләре башкарылган концерт заллары түгел, дип саналды. Традицион татар халык көе тумышы, яшәү шартлары, юнәлеше белән җиңел күңел ачу музыкасыннан ерак торса да, Илһам Шакиров, үзенең эчке сизгерлеге белән, татар халык көйләрендә андый мөмкинлекләрне дә күрде. Заманча яңгырау берникадәр җилбәзәк яшьләрдә халык көйләренә карата кызыксыну уятты, аларда милли хисләр сүнмәүгә бер сәбәп булды. Бу бигрәк тә шәһәр яшьләре өчен әһәмиятле иде» [18].

5. «Татар музыкасын башкару сәнгате өчен инде традицион булган кайбер алымнарга да Илһам Шакиров яңа төс бирә алды. Әйтик, баянга кушылып җырлау. Илһам Шакиров бер баян урынына – ике, ә кайбер очракларда өч баян белән чыга башлады. Баянчылар, әлбәттә, партияләргә бүленеп уйнамадылар. Алай да аларның уйнавы берсе-берсен кабатламады, ләкин алар нәкъ бер төсле уйнасалар да, бу беренче карауга гади генә бер ачыш музыкага көтелмәгән колач бирде. Баян тавышы дулкыннары бөтен залны тутырып алгандай әллә нинди стерео эффект тудырдылар, киң, мәһабәт, көчле яңгыраш барлыкка килде» [18].

6. «Илһам Шакировның кыю адымнарының берсе – халык көйләрен сәхнәдә ялгыз җырлау. Мондый рәвештә "Иске караурман", "Әллүки", "Урал" кебек озын көйләр җырлануны истә тотсаң, бу адымның бигрәк тә җаваплы икәнең күрәсең. Чөнки сәхнә өчен бик озын, бер гомер итеп тоелган 4-5 минут эчендә япа-ялгыз, музыка коралларының бизәкләреннән тыш кеше тавышы гына яңгырый. Үзен, ялыктырмыйча тыңлатыр өчен, җырчы бик оста, аның тавышы матур һәм төсмерләргә бай булырга тиеш. Кайвакытта Илһам Шакиров үзенең вокализ-импровизацияләрен дә ялгыз җырлый, бигрәк тә симфоник оркестр белән, чөнки зур коллектив җырчының импровизациясенә кушылып, үзе дә импровизацияләп уйный алмый, ул тынып кала. Мондый вакытта оркестр аккомпонементы белән башкарылган җыр әсәре кеше тавышы һәм симфоник оркестр өчен концертны хәтерләтә башлый, чөнки җырчы тавышы әле генә яңгыраган бик күп музыка коралларын туплаган оркестрга каршы куела. Ялгыз тавыш оркестр белән ярыша. Тыңлаучының бөтен игътибарын бер ноктага текәп, читкә тайпылдырмыйча, ялгыз җырлау – бик зур артистка гына хас алым. Шуны да әйтергә кирәк: ялгыз җырлау, гадәттә, җырчының иҗади логикасын, трактовкасын таләп итә. Әйтик, "Иске караурман"да халыкның ялгызлыгын, ярдәмсезлеген күрсәтә» [18].

7. «Илһам Шакировның татар җыр сәнгатенә керткән яңа алымнары үз тавышының мөмкинлекләрен күрсәтү белән мавыгудан түгел, ә иҗади проблемаларны хәл итүдән килә. Җырчы гына түгел, артист буларак, ул әсәрнең музыка һәм шигъри эчтәлеген тулысынча ачуга омтыла һәм шул омтылышта яңа чаралар таба. Илһам Шакиров репертуарны сайлый белә: бардан сайлау гына түгел, ул татар халкы җыр-көй репертуарын искиткеч баетты, беркемгә дә билгеле булмаган әсәрләрен табып, музыкаль көнкүрешкә кертеп җибәрде, халыкның музыкаль кузаллавын киңәйтте» [18].

Нәкый Исәнбәт «Телевизор алдында уйланулар» (1971) исемендәге хезмәтендә Илһам Шакировның ни дәрәҗәдә үз эшенә җаваплы караганы турында хәтирәләр белән уртаклаша. Телеоператорлар төшерү осталыгы түбән дәрәҗәдә булганлыктан, галим фикеренчә, телевизорлар Илһам Шакировны «башта ничә ел буе чыра урынына телделәр». «Ничә мәртәбәләр баш түбәсен яньчеп, маңгаен уеп алып, кешене безгә ни бары ике чигә сакалы белән генә күрсәтеп тоттылар» [19, б. 3]. Эшнең мондый куелышы белән канәгать булмаган бөек җырчы, студиягә ике көн алдан килеп, бөтен төшерү мәйданчыгын сантиметрлап үлчәп, «үзен генә түгел, бригадасын да кайсын кая нинди шахматта бастырып, нинди шәүлә-күләгәләр төшертергә

номерлап яздыртып, җитәкчелектән шуңа «подпись салдырып» ала башлады. Нәтиҗәдә аның «Идел» ансамбле экраннан «сәнгатьчә композицион күренеш» алып, тамашачыга «күңелле тәэсир калдыра» иде [19, б. 3]. Илһам Шакировка ут төшкәч, җырчы «Бүген һәйбәт костюмнан»; «Үзе дә пөхтә кырынган»; «Маңгай ачык, йөзе дә чыраена муафыйк» күрергә була иде [19, б. 1].

Академик Миркасыйм Госманов җыр сәнгатебезгә Илһам Шакиров китергән яңалыкларның тагын бер төрен әйтеп китә: «Мин аның аерым этнографик төркемнәребездә, киң таралган диаспораларыбызда эзләнүләр алып барып, җыр хәзинәсен баетуын, шул юл белән күптармаклы халкыбызның бербөтен милләт икәнлеген өстәмә рәвештә раславын махсус әйтер идем» [1, б. 52]. Илһам Шакиров Финляндия татарларыннан – Нәкый Исәнбәтнең «Туган ил» көен, Кытай татарларыннан Дәрдмәнд сүзләренә җырланучы «Кораб» дигән халык җырын алып кайта.

Егерменче гасырның алтмышынчы елларында Казахстанда һәм Алма-Ата каласында «Татар әдәбияты һәм сәнгате көннәре» үтте. Анда татар артистларының бик күп концертлары булды. «Кытайдан Алма-Атага күченеп килгән татарлар бу концертларның берсен дә калдырмыйча йөрделәр. Илһам Шакиров җырлавы аларга бомба шартлагандай тәэсир итте – җырчы тавышының гүзәллеге, көче, моңы иксез-чиксез иде», – дип, бу вакыйга турында истәлекләре белән бүлешә Кытай татарларының милли хәрәкәте вәкиле Р. Сәфәргалиев [20]. Казахстан тамашачысы Илһам Шакировны беренче тыңлауда ук аның иҗатына гашыйк булды. Алар җырчының гастроль маршруты белән алдан кызыксынып, аның концертларына тамашачы килүен оештыруны, артистларны лаеклы рәвештә каршылауны, озатып җибәрү эшләрен үз өсләренә алганнар.

1965 елда Илһам Шакиров татар җәмгыяте вәкилләрен Казанга кунакка чакыра. Җырчы Р. Сәфәргалиевкә, Казахстанның сәнгать эшлеклесе, рәссам Бәхтияр Табига, фәннәр кандидаты, профессор Шамил Хәкимовка тимер юл билетларын үзе сатып алып җибәрә. Илһам Шакиров кунакларны Казан тимер юл вокзалында каршы ала һәм туры татар зиратына алып китә. Алар бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның, Шиһабетдин Мәрҗани һәм башка тарихи шәхесләрнең каберләрен зиярәт кылганнар.

Шул ук көнне җырчы кунакларны, Фәннәр академиясенә алып барып, музыка белгече Мәхмүт Нигъмәтҗанов, сәнгать белгече, архитектор, тарихчы Фуад Вәлиев белән таныштыра. Очрашу вакытында Илһам Шакиров «Р. Сәфәргалиев Кытайдан ук алып килгән, бөек шагыйребез Дәрдмәнд сүзләренә җырланучы “Кораб” дигән халык җырын башкарган» [20, б. 112]. Соңыннан бу җырны җырчы радиода һәм сәхнәдә еш башкара.

Нәтиҗә ясап, без дә абруйлы музыка белгеченең түбәндәге фикеренә кушылабыз: «Илһам Шакиров – татар музыка сәнгатендә аерым бер зур урын тоткан музыкант. XX йөз бетеп килә, ул – татар профессиональ музыка сәнгатенең беренче йөз еллыгы. Шул дәвердә дөнья музыка сәнгатенә нәрсә бирә алдык? Уйлый башласак, бары тик бер-ике әсәр, бер-ике аерым исем искә төшә. Шул кадерле шәхесләр арасында Илһам Шакиров исеме дә бар. Гадәттә, теләсә кайсы халыкның фольклор музыкасын чит илләрдә кызыксынып тыңлыйлар. Бөтен дөньяда танылган музыка дәрәҗәсендә булудан түгел, ә могҗиза, экзотик нәрсә дип. Татар халык музыкасын эшкәртү, чын сәнгать дәрәҗәсенә күтәрү бурычын Илһам Шакиров үтәде. Аның язмалары – XX гасыр профессиональ татар сәнгатенең иң нәтиҗәле казанышларыннан, безнең горурлыгыбыз, киләчәгебез, бөтен дөнья музыка сәнгатенә керү юлында нигез ташы» [18].

Мәкалә йомгагында без татар мәдәнияте, шул исәптән этномузыкология өлкәсендә дә зур казанышларга ирешкән Нәкый Һәм Йолдыз Исәнбәтләрнең югарыда китерелгән фикерләре татар музыкологиясенең халыкчан башкару юнәлешен өйрәнү өчен теоретик нигезләр булырлар һәм фәндә үз урыннарын табарлар һәм Илһам Шакиров иҗатын өйрәнүчеләргә дә тиешле юнәлеш бирерләр дигән фикердә калабыз. Моңа кадәр бу өлкәдә Ә.Х. Абдуллинның гына хезмәте билгеле иде [21].

**Әдәбият**


1. «Илаһи Илһам»: Илһам Шакировның тууына 85 ел. Казан: Җыен, 2020. 184 б.
2. *Исанбет Ю.* Статья Наки Исанбета «На путях становления татарской музыки (1923)» как источник научного комментирования // Tatarica. 2021. №2 (17). 141–168 б.
3. *Исанбет Н.* «Коңгыр бога» көе: тарихи тамырлары һәм поэтикасы төрки халыклар

мәдәнияте контекстында // Tatarica. 2021. №2 (17). 141–168 б.

4. *Исәнбәт Н.* Казан артына беренче сәяхәтем: «Оры аккан» // Tatarica. 2023. № 2 (21). 76–100 б.

5. *Исәнбәт Н.* Көй, җыр, биюләр ничек килеп чыга // Исәнбәт Н. Ни өчен ни булган яки утыз ялган. Казан: Татар. кит. нәшр., 1956. 98–102 б.

6. *Исәнбәт Н.* Ф. Кудашева концертлары // Совет Татарстаны. 1959. 20 май.

7. *Исәнбәт Н.* Бер татар авылының моннан йөз ел элек язылган җыр-көйләре // Казан утлары. 1966. № 11. 141–151 б.

8. *Исәнбәт Н.* Халык көйләре, исемсез композиторларыбыз хакында // Татар музыкасы турында гыйльми хезмәт // Нәкый Исәнбәт шәхси архивыннан. Кулъязма. Датасыз. 10–13 б.

9. *Фәхретдинов Р.* Җырчы: (Илһам Шакиров). Казан: Татар. кит. нәшр.,1973. 78 б.

10. Илһам. / төз. Р. Вәлиев. Казан: Татар. кит. нәшр, 1995. 128 б.

11. Илһам Шакиров: фәнни-популяр җыентык / төз. М. Галиев. Казан: Җыен, 2020. 536 б.

12. *Шакиров И.* Яклыйбыз // Социалистик Татарстан. 1968. 14 апрель.

13. Письмо Р.Яхина С. Вельшаковой от 16 июня 1968 г. // Рустем Яхин: Материалы. Письма. Воспоминания / Сост. Ю.Н. Исанбет, К.С. Тазиева. Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. С.152–153.

14. *Беляев Р. Ф.* Татарская диаспора Финляндии: вопросы интеграции и сохранения идентичности: дис. … докт. филос. наук. Хельсинки, 2017. 310 с.

15. *Исәнбәт Н.* Туган ил : [шигырь] // Балалар дөньясы. 1917. 1 март. № 1. 1 б.

16. *Исәнбәт Н.* Син сазыңны уйнадың: «Моңланып ай нурларында…» // Исәнбәт Н. Сайланма әсәрләр. 4 т. 1 т. Казан: Татар. кит. нәшр., 1989. 110 б.

17. Шәһри Казан : түгәрәк өстәл / Язманы Рәмис Аймәт һәм Әгъзам Фәйзрахманов әзерләде // Шәһри Казан. 1995. 11 апр.

18. Илһам Шакировка 60 яшь / Радиотапшыру / алып баручы – музыка белгече Й. Исәнбәт // Татарстан радиосы архивыннан. 1995 ел. // URL: https://vk.com/dtrk_tatarsatan?ysclid=m9s3xd444b754100359 (мөрәҗәгать итү вакыты 20.02.2025 )

19. *Исәнбәт Н.* Телевизор алдында уйланулар // Н. Исәнбәтнең шәхси архивыннан. Кульязма. 1971 ел. 20 б.

20. *Сәфәргалиев Р.* Илаһи әмер белән дөньяга килгән талант // Казан утлары. 2010. №2. 111–113 б.

21. *Абдуллин А. Х.* Татарская народная песня: Тематика, жанры и некоторые особенности народного исполнительства: диссертация ... канд. искусствоведения: 17.00.00. [Ленинград], 1971. 258 с.